РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Солнечный бульвар, дом 7,
с.Большие Кайбицы, 422330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Кояшлы бульвар,. 7 йорт,
Олы Кайбыч авылы, 422330

тел.: (8-84370) 2-11-01, тел./факс: (8-84370) 2-11-85, e-mail: Kaybicy.Admin@tatar.ru, www.kaybici.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

«30» сентябрь 2022 ел Олы Кайбыч ав. №143

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән тәртипле һәм нәтиҗәле файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы, 2014 елның 27 сентябрендәге 2022 номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге https://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин